ГЛАВНОЕ
АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ПРИ КАБИНЕТЕ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
(ТАТГЛАВАРХИВ)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
КАРШЫНДАГЫ
БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ
(ТАТБАШАРХИВ)

# БОЕРЫК

19.08.2013 Казан № 039

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә вакантлы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында» 2007 елның 11 июлендәге 013 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны гамәлдәге Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә вакантлы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында» 2007 елның 11 июлендәге 013 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә вакантлы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә.

Күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә вакантлы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмәдә:

2.1 пунктта:

«в» пунтчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Федарель законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен башка дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә»;

җиденче абзацта «Россия Федерациясе Президенты указы белән» сүзләрен «Идарә боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта:

алтынчы абзацта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бәйсез экспертлар сыйфатында фән һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар вәкилләре җәлеп ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясе составына Идарә каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре кертелә. Бу вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына кертү өчен Идарә каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары Идарә башлыгы соравы буенча әлеге совет тарафыннан тәкъдим ителә.»;

Нигезләмәнең 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокукка ия дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын аның граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.».

Башлык Д.И. Ибраһимов